РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛАННИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАЛАННЫАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Баланны авылы

22 май 2024 ел

**КАРАР № 17**

**2024-2028 елларга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа хуҗалык кенәгәләрен электрон формада салу һәм алып бару турында**

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 07.07.2023 елгы 112-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «хуҗалык кенәгәләрен алып бару формасын һәм тәртибен раслау турында» 27.09.2022 елгы 629 номерлы боерыгы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының баланна авыл җирлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу турында

КАРАР БИРӘМ

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баланна авыл җирлеге территориясендә 2024-2028 елларга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа хуҗалык кенәгәләрен электрон формада салуны оештырырга, авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең бухгалтерлык һәм махсуслаштырылган хисапларын җыюның һәм эшкәртүнең, Җыелма Хисаплар төзүнең, мониторингның, исәпкә алуның комплекслы мәгълүмат системасын кулланырга, агросәнәгать комплексына ярдәм итүгә субсидияләрне контрольдә тоту һәм анализлау.

2. Ел саен 1 гыйнварга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тоташ карап чыгу һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар (алга таба - шәхси ярдәмче хуҗалыклар) әгъзаларыннан сорашып белешү юлы белән 10 гыйнвардан 15 февральгә кадәр китапларда күрсәтелгән белешмәләрне җыярга. Шәхси ярдәмче хуҗалыклар турындагы белешмәләрнең эчтәлеге, шәхси ярдәмче хуҗалыклар турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, шәхси ярдәмче хуҗалыклар әгъзалары инициативасы буенча башка даталарга төгәлләштерелергә мөмкин.

3. Хуҗалык кенәгәләренә язуларны шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы яисә шәхси ярдәмче хуҗалыкның башка әгъзалары тарафыннан ирекле нигездә бирелә торган белешмәләр нигезендә башкарырга.

4. Хуҗалык кенәгәләрен алып барганда шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып бару өчен рөхсәт ителгән җир кишәрлеге бирелгән һәм (яисә) сатып алынган гражданнар тарафыннан бирелә торган мәгълүматның конфиденциальлеген, аның сакланышын һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә яклауны тәэмин итәргә кирәк.

5. Электрон хуҗалык китапларын билгеләнгән тәртиптә алып бару һәм аларның сакланышы өчен җаваплы итеп Д. М. Гыйзетдиновны билгеләргә.. - Баланна авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы.

6. Әлеге карарны Баланна авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

8. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Баланны авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Гильфанова И.Х.